Алдаунын яна ысулы: ни очен мошенниклар vз корбаннарына акча kvчерә

Галинанын ире банк картасына 5500 сум акча килгән.
Бу хакта белми дә калган иргә чит-ят номердан бер хатын шалтыратып хәбәр итә. Янәсе: «Ялгыш кына сезгә акча kvчердем. Кире kvчерегез әле», ди мошеннник.

Галина бу хакта белеп алгач, тиз генә әлеге номерны блокка кертә. Бу - мошенниклар эше дип уйлый хатын һәм ялгышмый. Сонрак 900 номерыннан смс хәбәр килә (кешене алдау технологияләре ярдәмендә мошенниклар яшеренгән Саклык банкынын рәсми номеры). Әлеге язуда жибәрелгән кодны билгеле бер сайтта кертергә кирәк, дип язылган була.
Галина ире белән банкнын якындагы бvлекчәсенә бара. Анда алар мошенникларнын әлеге гамәле турында гариза язалар. Хезмәткәрләр счеттан 5500 сум акча алалар һәм Галинаны, анын ирен уяулыклары очен мактыйлар.
Мондый очраклар була калса, акчаны кире жибәрергә ярамый, барысы да рәсми рәвештә банк аша булырга тиеш.
“Дәшми–тынмый гына акчаны vзендә калдырырга ярамый. Бу әхлаксызлык, шулай ук законсыз баю буларак танылырга момкин. Мондый очракларда картасына акча жибәрелгән кеше жаваплылыкка тартылачак”, - ди банк олкәсендәге белгеч.

Ләмбердә яшәvче хатын мошенникларга 700 мен сумнан артык акча kvчергән

21 августта мессенджер ярдәмендә ана билгесез кулланучыдан кунакха-нәләр рейтингын алга жибәрv белән бәйле остәмә хезмәт хакы турында тәкъдим белән хәбәр килгән.
Язышудан kvренгәнчә, кыз кунак-ханәләрне шәхси акчага броньларга тиеш булган, аннары ул әнгәмәдәш жибәргән сылтамалар буенча сайтларына kvчкән. Кунакханәләр сурәтләре белән скриншотлар жибәрергә тиеш булган. Шунын белән ул янәсе аларнын рейтингын kvтәргән. Шул ук вакытта морәжәгать итvче һәр броньлаудан элек кертелгән суммалар белән бергә алардан процентлар да алырга тиеш була. Башта броньнын kvләме 20 мен сумнан артмаган, ә берничә биремнән сон ана яна kvрсәтмә килгән: берьюлы берничә кунакханәне броньларга кирәк булган.
Финанс операцияләрен уздырганнан сон ана биремнәрнен vтәлеше турында хәбәр килә. Кыз акча чыгарырга тырышып караган, ләкин булдыра алмаган. Мошенниклар корбаны булуын анлап, гариза бирvче полициягә морәжәгать иткән. Шулай итеп, зыян kvрvчегә китерелгән зыяннын гомуми суммасы 700 мен сумнан артып киткән.
Хәзерге вакытта жинаять кылуга катнашы булган затлар билгеләнә. Мордовия Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы гражданнарнын игътибарын жәлеп итә:

товарны яки хезмәтне онлайн-сатып алганда, компаниянен рәсми сайтыннан гына файдаланыгыз. Шулай ук хезмәт яки товар очен аларны алганнан сон гына түләргә тырышыгыз.